КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 август г.Казань № 643

Футбол буенча Россия Кубогы матчын үткәрү көнендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны чикләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Казан шәһәрендә «Рубин» (Казан шәһәре) – «Зенит» (Санкт-Петербург шәһәре) командалары арасында футбол буенча Россия Кубогы матчын үткәргәндә иминлекне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 13 һәм 14 августында әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән территорияләр чикләрендә, шулай ук Казан шәһәренең Астрономия, Бауман, Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Профсоюз, Университет, Чернышевский урамнарындагы сәүдә объектларында алкогольле продукцияне ваклап сату (җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатудан тыш) рөхсәт ителми дип билгеләргә.

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, кертелә торган чикләү турында халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга.


3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә һәм, килештереп, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына йөкләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 10 август, 643 нче
карарына кушымта

Казан шәһәрендә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләр чикләре




Урамнарның чикләре: С.Хәким урамыннан алып Чистай урамына кадәр Әмирхан проспекты буенча, Чистай урамы буенча Адоратский урамына кадәр, Адоратский урамы буенча Лаврентьев урамына кадәр, ишегалды территорияләре буйлап Лаврентьев урамы буенча Гаврилов урамы, 10 нчы йортка кадәр, алга таба 3 нче транспорт дамбасының әйләнеп уза торган күпере чиге буенча («Мегастрой» кибетен кертеп) Троицкий урманы урамына кадәр, Троицкий урманы урамы буенча, алга таба Казансу елгасының су акваториясе кыры буйлап Әмирхан проспектына кадәр.

_______________________